КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ **БОЕРЫК**

2020 ел, 12 март г.Казань № б-925

Россия Федерациясе Җир кодексының 70[1] нче статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлауга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервлау турында» 2004 елның 22 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фонды һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү һәм аларны алга таба файдалану мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2005 ел, 21 гыйнвар, 15 нче карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фондының 1 нче кушымтада күрсәтелгән 0,7267 гектар гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – җир кишәрлекләре) аларны дәүләт ихтыяҗлары өчен файдалану максаты белән Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына өч елга кертү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

җир кишәрлекләрен резервлау Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Голубятников урамы, Стадион урамы буенча җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына күчерү турында» 2016 елның 28 декабрендәге 5351 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла;

резервлана торган җир кишәрлекләре схемасы белән кызыксынучы затларны таныштыру көн саен (шимбә, якшәмбе һәм эш көннәре булмаган бәйрәм көннәреннән тыш) 8 сәгать 00 минуттан 12 сәгать 00 минутка кадәр һәм 13 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр Казан шәһәре, Академик Губкин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фонды бинасында гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу боерыкның 1 нче пункты нигезендә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләрне керту өчен документларны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 13 март, б-429 нчы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

6. Бу боерык резервлана торган җир кишәрлекләре урнашу урыны буенча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш һәм басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 12 май, б-925 нче
боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы җирләренең
дәүләт резервына кертелә торган җир кишәрлекләре
исемлеге

Урнашу урыны	Җирләр категори-ясе	Кадастр саны	Мәйданы, гектар
Казан шәһәре, Совет районы	торак пунктлар җирләре	16:50:250245:222	0,3755
Казан шәһәре, Яңа Савин районы	торак пунктлар җирләре	16:50:110403:3749	0,3512
		Барлыгы	0,7267

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 12 май, б-925 нче
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына
кертелә торган 16:50:250245:222 кадастр санлы җир кишәрлегенең
схемасы



Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 12 май, б-925 нче
боерыгына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына
кертелә торган 16:50:110403:3749 кадастр санлы җир кишәрлегенең
схемасы